Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советының унөченче утырышы

Күн авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

14 декабрь, 2021 ел

№ 35

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге уставының 21.1 статьялары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советы карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советының 2019 елның 8 ноябрендәге 141 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмә исемендә «торак пунктларда» сүзләреннән соң «(торак пункт территориясе өлешендә)» сүзләрен өстәргә.

1.2. Нигезләмәнең преамбуласында «торак пунктларда» сүзләреннән соң «(торак пункт территориясе өлешендә)» сүзләрен өстәргә.

1.3. «Гомуми нигезләмәләр» 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт өстәргә:

«1.6. Татарстан Республикасы Законы нигезендә гражданнар җыены җирлек составына керүче торак пункт территориясе өлешендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелергә мөмкин.».

1.4. «Гражданнар җыены тәртибе» 3 өлешендә:

а) 3.1 пунктындагы өченче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«- гражданнар җыенында катнашу хокукына ия, сайлау хокукына ия, кимендә

10 кеше булган торак пунктта (торак пункт территориясенең тиешле өлешендә) яшәүчеләр төркеменә (ягъни Россия Федерациясенең хокукый сәләтле гражданнары, әлеге торак пунктта 18 яшькә житкән яшәү урыны буенча теркәлгән даими яисә күбесенчә әлеге торак пункта яшәүче, шулай ук торак пункт территориясендә (торак пункт территориясенең бер өлеше) даими яисә күбесенчә әлеге торак пункта яшәүче һәм жирле үзидарәне Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре һәм федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырганда хокуклы чит ил гражданнары).»;

б) 3.2 пунктта. «торак пункт халкы» сүзләреннән соң «(торак пункт территориясенең бер өлеше)» сүзләрен өстәргә.

1.5. 4 өлештә «Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе»:

а) 4.1 пункт. түбәндәге эчтәлекле икенче, өченче һәм дүртенче абзацлар өстәргә:

«Торак пункт территориясе өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены авыл җирлеге Советы тарафыннан 10 кешедән дә ким булмаган торак пункт территориясенең тиешле өлешендә яшәүчеләр инициативасы белән чакырыла.

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены уздырыла торган торак пункт территориясенең бер өлеше чикләре җирлек Советының җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләне хәл итүдә торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләре бергәлеге критериеннән чыгып билгеләнә. Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча җыеннар үткәрелергә мөмкин булган торак пункт территориясенең бер өлешенең чикләре өзелмәгән булырга, территориянең әлеге өлеше чикләрендә урнашкан торак пункт чикләреннән чыгу мөмкинлеген булдырмаска тиеш. Теркәлгән гражданнарның яшәү территориясе: урам (урамнар), күпфатирлы йорт (күпфатирлы йортлар), торак йортлар төркеме.

Торак пункт территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыенны этаплап үткәрү каралмаган.»;

б) 4.2 пунктта «(2, 3 нче кушымталар)» сүзләрен «(2, 2.1, 3 нче кушымталар)» фразасына алмаштырырга;

в) 4.7 пунктта «Торак пунктта яшәүчеләр» сүзләреннән соң «(торак пункт территориясе өлеше)» сүзләрен өстәргә.

1.6. «Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе» 5 өлешенә:

а) 5.1 пунктында «торак пунктта яшәүчеләр исемлеге» сүзләреннән соң «(торак пункт территориясе өлеше)» сүзләрен өстәргә;

б) 5.3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Сайлау хокукына ия торак пунктта (торак пункт территориясенең бер өлеше) яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче (торак пункт территориясенең бер өлеше) шушы Җирлек башлыгы тарафыннан теркәлергә һәм җыенда катнашуга кертелергә мөмкин.»;

в) 5.5 пунктында «торак пунктта яшәүчеләрнең» сүзләреннән соң «(торак пункт территориясе өлеше)» сүзләрен өстәргә;

г) 5.10 пунктының 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) жыенга килгән торак пунктта яшәүчеләрнең (торак пункт территориясе өлеше) теркәлүенең дөреслеген, кирәк булганда аларның гражданнар жыены эшендә катнашу хокукы булуын тикшерә;».

1.7. «Гражданнар җыены карарларын үтәү» 7 өлешенең 7.1 пунктында «торак пункт территориясендә» сүзләреннән соң «(торак пункт территориясенең бер өлеше)» сүзләрен өстәргә.

1.8. Нигезләмәне 2.1 нче кушымта белән тулыландырырга. (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы                    Р.Г. Баһауов

Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлеге Советы карарына кушымта __ _______ 2021 ел №___

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 2.1 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советының ___________ утырышы

Күн авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

_______ 20____ел №____

Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең _________ торак пункты территориясе өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Күн авыл җирлеге уставының _______ статьялары, имзалар кәгазе нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. 20** елның __ __________дә (да) 00 сәг. 00 минутта Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге _________торак пункты территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Күн торак пункты территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү территориясе чикләрен түбәндәге территорияләр чикләрендә расларга: мәсәлән, _______ урамы буенча __ дан ____ кадәр пар санлы йортлар, __ дан ____ кадәр так санлы йортлар, _______, ________ тыкрыклары, _______ урам буенча __, ___ нче (нчы) йортлар; ______ урамы буенча __,__,__ нче (нчы) йортлар; һ. б.

3. «Сез 20__ елда Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге _________ торак пункты территориясе өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән ____ сум күләмендә үзара салым кертүгә, (үзара салымнан азат ителгән гражданнар категориясен күрсәтергә) бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- ________________________________

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Күн авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы ____________